**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА БИЛЯР-ОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЛӘРКҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биләркүл ав. **КАРАР**

«10» ноябрь 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Зирекле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Биләркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Мәктәп урамы, 34Г йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Мәктәп урамы 1-64, Молодежная урамы 2-54нче йортларда яшәүче гражданнар өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Зирекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Мәктәп урамы, 34Г йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Полевая урамы 1-41, Речная урамы 1-43нче йортларда яшәүче гражданнар өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге Зирекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән  көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Зирекле авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ;
- Зирекле авылында урамнарны яктырту җайланмасы.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биләркүл авыл җирлеге башлыгы В.С.Оренбургов